

Россия кvпмилләтле дәvләт. Һәр милләт - ул кабатланмас милли мәдәният, тарих, традицияләр. Мор-довиядә торле милләт, дин кешеләре тату яши. Һәр халыкнын vз йолалары, гореф-гадәтләре, костюмнары бар. Кvршеләре белән тынычлыкта яшәр очен, кешеләр бер-берсенен vзенчәлекләрен, традицияләрен һәм мәдәниятен белергә тиеш. Шулай, vткән атнада Мордовия республикасы сукырлар очен махсус китапханәсендә «Ислам мәдәни vзәге» белән берлектә, «Ижади остаханә» клубы кысаларында «Татар халык орнаменты» мастер-классы узган. Чара барышында татар халык орнаменты барлыкка килv тарихы турында документаль фильм кvрсәтелгән. «Зәйнәб» татар ательесы житәкчесе, Мордовия татар хатын-кызларынын «Чулпан» ижтимагый оешмасы әгъзасы Рима Фатих кызы Байгельдина орнаментнын һәр элементы әһәмияте турында сойләп, татар милли костюмын кvрсәткән. Барлык катнашучылар татар костюмына ап-пликациянен аерым фрагментларын әзерләvдә катнашканнар һәм матур итеп чигелгән баш киемнәрен киеп тә карый алганнар. «Мәдәниятнен чиге юк, әмма традицияләре бар» дигән фольклор кичәсе дә биредә vткән. Китапханәдә бәйрәмнен топ геройлары - Кривозерье урта мәктәбе укучылары белән укытучылары булган. Тамашачылар укучылар башкаруында татар телендә шигырьләр тынлаганнар, татар әкиятенә нигезләнгән «Оч апа» спектаклен караганнар. Педагогик коллектив башкаруында әни турында лирик жырлар янгыраган. Фольклор бәйрәме татарларнын музыкаль-шигъри фольк-лоры, татар халык костюмы формалашу тарихы белән якыннан танышырга момкинлек биргән, милли татар чигvләренен серләрен һәм башка кvп нәрсәләр белән якыннан танышканнар.

**Наилә НАСЫРОВА**